ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02.06.2025 ел Баулы шәһәре №69

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 25 июлендәге 240 номерлы карары белән расланган, Баулы муниципаль районы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервлары турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервларын булдыру турында» 2008 елның 11 июлендәге 488 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервлары турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 1 февралендәге 49 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 25 июлендәге 240 номерлы карары белән расланган, Баулы муниципаль районы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервлары турындагы Нигезләмәгә (2023 елның 20 апрелендәге 101 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

II «Матди ресурслар резервларын булдыру, саклау, файдалану һәм тулыландыру тәртибе» бүлегендә:

2.6. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6. Гадәттән тыш хәлләрне ликвидацияләү өчен матди ресурслар резервлары, гадәттән тыш хәлләрне ликвидацияләгәндә кешеләр гомеренә һәм сәламәтлегенә турыдан-туры куркыныч янауны бетерү буенча авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләр башкару өчен, зыян күргән гражданнарны вакытлыча урнаштыру һәм тукландыру

пунктларын урнаштыру һәм тәртиптә тоту өчен, халыкка бер мәртәбә бирелә торган матди ярдәм күрсәтү өчен, зыян күргән халыкның тормыш эшчәнлеген тәэмин итү белән бәйле рәвештә, шулай ук, башка беренчел чаралар өчен файдаланыла.

Гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервлары, дәүләт матди резервыннан тыш, югары әзерлек режимы кертелгәндә файдаланылырга мөмкин.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров